**МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.05.2019 Казан ш. № 242

Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына максатчан билгеләнешле бүтән бюджетара трансферт бирү турында килешү формасын раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 елның 29 августындагы 614 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле бүтән бюджетара трансферт күчерү өчен боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле бүтән бюджетара трансферт бирү турында килешүнең әлеге Боерык кушымтасында каралган үрнәк формасын расларга.

2. Территориаль үсеш идарәсенең муниципаль берәмлекләрне үстерү бүлегенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының Башкарма комитетлары белән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле бүтән бюджетара трансферт бирү турында килешүләр әзерләүне;

әлеге боерык һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 елның 29 августындагы 614 номерлы карары таләпләренә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы муниципаль районнары Башкарма комитетларыннан хисаплылык җыюны.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Максатчан билгеләнеше булган башка бюджетара трансфертны Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү турында килешү формасын раслау хакында» 2018 елның 4 июнендәге 249 номерлы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары А.Д.Шәмсиевка йөкләргә.

5. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Министр** **Ф.С Габделганиев**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 22.05.2019 № 242 боерыгына кушымта

Үрнәк формасы

**Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле Бүтән бюджетара трансферт бирү турында №___ КИЛЕШҮ**

Казан ш.

«____»_______________20____ел. №_______

Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына максатчан билгеләнешле бүтән бюджетара трансферт бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары алга таба аларны Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларыннан Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре бюджетларына җибәрү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык) исеменнән, ул Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы булып тора, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 23 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә таянып эш йөртүче Татарстан Республикасы икътисад министры___________________________, бер яктан, һәм________________________ ____________________муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) исеменнән Уставка/Нигезләмәгә таянып эш йөртүче____________ ____________________________ муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе _________________________, икенче яктан (алга таба икесе дә бергә килгәндә – Яклар), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 елның 29 августындагы 614 номерлы карары (алга таба – Тәртип) һәм Татарстан РеспубликасыМинистрлар Кабинетының 20____ елның ____________, ________ номерлы күрсәтмәсенә нигезләнеп, түбәндәгеләр хакында әлеге Килешү төзеде.

## 1. Килешүнең предметы

1.1. Әлеге Килешүнең предметы Татарстан Республикасы бюджетыннан тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чигендә

Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларыннан Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре бюджетларына җибәрү өчен Татарстан Республикасы муниципаль районы бюджетына җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бүтән бюджетара трансфертны (алга таба – Бүтән бюджетара трансферт) бюджетлар чыгымнары классификациясе кодлары буенча бирүдән гыйбарәт: Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүченең коды______, бүлекчәсе ______, максатчан статьясы ________, чыгымнар төре ______ косгу ______ әлеге Килешүнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга.

1.2. Бүтән бюджетара трансферт бирү Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән авыл җирлекләренә һәм шәһәр җирлекләренә ел саен Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән авыл җирлекләренә һәм шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә уздырыла торган Республика конкурсы (алга таба – Конкурс) йомгаклары буенча гамәлгә ашырыла, түбәндәге максатларда:

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләре һәм шәһәр җирлекләре җирле үзидарә органнарының халыкның тормыш сыйфатын күтәрү буенча эшчәнлегенә этәргеч бирү өчен;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләренең һәм шәһәр җирлекләренең социаль әһәмиятле проблемаларын хәл итү өчен;

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә өстәмә ресурслар җәлеп итү механизмнарын камилләштерү өчен.

1.3. Бүтән бюджетара трансферт Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган авыл җирлекләренә һәм шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә Республика конкурсында җиңүчеләргә Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган, шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләренең һәм шәһәр җирлекләренең турыдан-туры тормышны тәэмин итү объектларының матди-техник базасын ныгыту, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган, шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләрен һәм шәһәр җирлекләрен социаль инфраструктура һәм тышкы төзекләндерү объектлары белән җиһазландыру һәм әлеге Килешүгә 1 нче кушымтага туры китереп, чаралар исемлеге һәм әлеге Килешүнең 2 нче кушымтасына туры китереп, аның аерылгысыз өлеше булып торган Бүтән бюджетара трансфертны тоту юнәлешләре исемлеге нигезендә башка Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган, шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләренең һәм шәһәр җирлекләренең башка төрле социаль әһәмиятле мәсьәләләрен хәл итү чараларын тормышка ашыру өчен бирелә.

## 2. Бүтән бюджетара трансферт бирү һәм күчерү тәртибе, шартлары

2.1. Бүтән бюджетара трансферт тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чигендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 20 ____ елның «___»___________ №_______ боерыгы белән расланган Бүтән бюджетара трансферт бүленеше нигезендә бирелә.

2.2. Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районы бюджетына бирелә торган Бүтән бюджетара трансфертның гомуми күләме 20 ______ елда ___________ (____________________________________) сум___ тиен.

2.3. Бүтән бюджетара трансферт түбәндәге шарт булганда бирелә:

а) Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләре һәм шәһәр җирлекләре бюджетларына бүтән бюджетара трансфертлар бирү буенча Татарстан Республикасы муниципаль районының чыгым йөкләмәләрен билгеләүче, билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән Татарстан Республикасы муниципаль районы муниципаль хокукый акты булу;

б) Татарстан Республикасы муниципаль районының бүтән бюджетара трансфертлардан файдалану турында берләштерелгән хисап бирү турында йөкләмәсе булу.

2.3.1. Әлеге Килешүнең 2.3 пунктында каралган Бүтән бюджетара трансферт бирү шартларының үтәлүен раслый торган документлар Башкарма комитет тарафыннан Министрлыкка бер тапкыр тапшырыла.

2.4. ___________________ муниципаль районы Башкарма комитетына Бүтән бюджетара трансферт күчерү Министрлык тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органында җирле бюджетларның үтәлешенә касса хезмәте күрсәтелү өчен Килешү имзаланган датадан 10 эш көне эчендәачылган счетына башкарыла.

## 3. Якларның үзара мөнәсәбәте

3.1. Министрлык түбәндәгеләрне үтәү бурычын үз өстенә ала:

3.1.1. _______________ муниципаль районы бюджетына Бүтән бюджетара трансферт бирүне әлеге Килешүдә билгеләнгән Бүтән бюджетара трансферт бирү тәртибен саклап һәм аны бирү шартларын Башкарма комитет тарафыннан үтәп тәэмин итәргә.

3.1.2. _______________ муниципаль районы бюджетына Бүтән бюджетара трансферт бирүне әлеге Килешүдә билгеләнгән Бүтән бюджетара трансферт бирү тәртибен саклап һәм аны бирү шартларын Башкарма комитет тарафыннан үтәп тәэмин итәргә.

3.1.3. Законнарга нигезләнеп Тәртип нигезендә бирелгән Бүтән бюджетара трансфертның максатчан файдаланылуын тикшереп торуны Татарстан Республикас Финанс министрлыгы белән берлектә гамәлгә ашырырга.

3.1.4. Бүтән бюджетара трансфертның максатчан файдаланылуын раслый торган документларны тикшерүне гамәлгә ашырырга.

3.1.5. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча аңлатмаларны Башкарма комитетка әлеге Килешүнең 3.4.1 п. нигезендә Башкарма комитет мөрәҗәгате алынган көннән башлап 30 эш көне эчендә җибәрергә.

3.1.6. Татарстан Республикасы бюджет законнарында, Тәртиптә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка бурычларны башкарырга.

3.2. Министрлык хокуклары:

3.2.1. Бүтән бюджетара трансферт бирү шартларының һәм Килешүдә каралган бүтән бурычларның Башкарма комитет тарафыннан үтәлешен, шул исәптән Бүтән бюджетара трансферт бирү шартларын Башкарма комитет үтәве белән бәйле беренчел документацияне тикшереп торуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм материалларны Башкарма комитеттан соратып алырга.

3.2.2. Татарстан Республикасы бюджет законнарында, Тәртиптә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

3.3. Башкарма комитет түбәндәге йөкләмәләрне ала:

3.3.1. Хисап кварталыннан соң килә торган айның 7 көненә кадәрге срокта Министрлыкка финанс белән тәэмин итү чыганагы Бүтән бюджет трансферты булган чыгымнар турында вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан таныкланган хисапны, аның язма формасы әлеге Килешүгә 3 нче кушымтада каралган, тотылган акчаны раслый торган документларның күчермәләре белән бергә квартал саен кулдан тапшырырга.

3.3.2. Хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр төп эш итүченең, эш итүченең, бюджет акчаларын алучының, баш администраторның, бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары администраторының, баш администраторның, бюджет керемнәре администраторының бюджетын үтәү турында хисапның (ОКУД 0503127 формасы) (Россия Финанс министрлыгының 2010 елның 28 декабрендәге 191н номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү турында еллык, кварталлык һәм айлык хисаплылыкны төзү һәм тапшыру тәртибе турында күрсәтмә нигезендә) һәм федераль бюджеттан бюджетара трансфертларны Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр һәм территориаль дәүләт бюджетара фонд тарафыннан файдалану турында хисапның (ОКУД 0503324 формасы) Министрлыкка тапшырылуын тәэмин итәргә. Күрсәтелгән хисаплар Министрлыкка субъектның финанс органы тарафыннан таныкланган кәгазь чыганакта кулдан тапшырыла.

3.3.3. Әлеге Килешүгә 3 нче, 4 нче кушымталарга туры китереп, Министрлык тарафыннан расланган форма буенча Бүтән бюджетара трансферттан файдалану турында ахыргы финанс хисабын хисап елыннан соңгы елның 1 февраленә кадәр Министрлыкка кулдан тапшырылуын тәэмин итәргә.

3.3.4. Таләп алынган очракта Башкарма комитет тарафыннан Бүтән бюджетара трансфертны бирү шартларының һәм әлеге Килешүдә каралган башка йөкләмәләрнең үтәлешен тикшерүдә тоту өчен кирәкле документларның һәм материалларның, шул исәптән Башкарма комитет тарафыннан Бүтән бюджетара трансферт бирү шартларын үтәүгә бәйле бухгалтерлык исәбе һәм беренчел документлар белешмәләренең Министрлыкка тапшыруны тәэмин итәргә.

3.3.5. Әлеге Килешүнең 4.4 п. нигезендә агымдагы финанс елының 1 гыйнварына тотылмаган бүтән бюджетара трансфертларны Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре кире кайтарырга.

3.3.6. Татарстан Республикасы бюджет законнарында, Тәртиптә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка бурычларны башкарырга.

3.4. Башкарма комитет түбәндәгеләргә хокуклы:

3.4.1. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә Министрлыкка аңлатмалар сорап мөрәҗәгать итәргә.

3.4.2. Татарстан Республикасы бюджет законнарында, Тәртиптә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

## 4. Якларның җаваплылыгы

4.1. Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен Яклар законнар нигезендә җаваплы була.

4.2. Бүтән бюджетара трансфертны түләү өчен бирелгән акчаларның максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаганлыгы ачыкланганда һәм (яки) төгәл булмаган хисаплылык тапшырылганда яки тапшырылмаганда, әлеге Килешү һәм Тәртип шартлары бозылган очракта Бүтән бюджетара трансферт 30 көнлек срокта Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кайтарып бирелергә тиеш.

4.3. Бүтән бюджетара трансфертны кайтару өчен билгеләнгән срок бозылганда, Министрлык Килешүнең 4.2 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланган көннән башлап 30 көнлек срокта Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Бүтән бюджетара трансфертның Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылуы буенча чаралар күрә.

4.4. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмаган Бүтән бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

4.5. Хисап финанс елында файдаланылмый калган Бүтән бюджетара трансфертка ихтыяҗ булу турында Министрлык карары нигезендә күрсәтелгән Бүтән бюджетара трансфертның калган өлешеннән артып китмәгән күләмдәге акчалар агымдагы финанс елында күрсәтелгән Бүтән бюджетара трансферт бирү максатларына туры килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен элек бирелгән Башкарма комитетка кире кайтарылырга мөмкин.

4.6. Әлеге Килешү нигезендә алынган Бүтән бюджетара трансфертларның кулланылмаган калдык өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемenә күчерелмәгән очракта, әлеге акчалар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгели торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә алынырга тиеш.

4.7. Форс-мажор шартлары килеп чыккан очракта яклар әлеге Килешү буенча бурычларны үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә.
Форс-мажор шартлары дигәндә, аңлы рәвештә гамәл кылучы Яклар үзләренә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында бурычларын тиешенчә үти алмаган шартлар башлануы турында аңлашыла, асылда, мондый шартларга Килешү буенча бурычларны тиешенчә үтәү мөмкинлеген бирми торган хәрби гамәлләр, стихияле бәла-казалар керә.

Форс-мажор хәлләре башланган очракта Яклар күрсәтелгән шартларның барлыкка килүе турында бер-берсенә өч көн эчендә хәбәр итәргә тиеш.

4.8. Башкарма комитет Бүтән бюджетара трансфертны максатчан файдалану, шулай ук әлеге Килешү нигезендә Министрлыкка тапшырылган хисапның дөреслеге, тулылыгы һәм вакытында тапшырылуы өчен җаваплы була.

4.9. Алынган Бүтән бюджетара трансфертны тотуга кагылышлы документлар тапшырылмаган очракта, Бүтән бюджетара трансфертны максатчан тотмаган очракта, шулай ук төгәл булмаган яки ялган документлар тапшырылган очракта Министрлык Килешүне вакытыннан алда таркату турында Башкарма комитетка хәбәр җибәрү юлы

белән, Килешүне бер яклы тәртиптә таркату хокукына ия.

4.10. Әлеге Килешүнең 4.9 пунктында күрсәтелгән хәбәр алынганнан соң, Башкарма комитет әлеге Килешүнең 4 бүлегенә туры китереп, Бүтән бюджетара трансферт суммасын Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарырга тиеш.

## 5. Ахыргы нигезләмәләр

5.1. Яклар арасында әлеге Килешүне үтәү белән бәйле барлыкка килә торган бәхәсләр алар тарафыннан, мөмкин булганча, беркетмәләр яки бүтән документлар рәсмиләштереп, сөйләшүләр үткәрү юлы белән хәл ителә. Килешүгә ирешелмәгән очракта, Яклар арасындагы бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

5.2. Әлеге Килешү үз көченә керә датасыннан һәм аны имзалау затлар булган исеменнән эш итәргә хокукы һәр Якның, һәм 31 декабренә кадәр гамәлдә _______ елның чынлап Килешүе. Килешүнең гамәлдә булуын туктату яклар әлеге Килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәүдән азат итми.

5.3. Килешүгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр, әгәр алар язма рәвештә төзелгән һәм якларның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган очракта гына гамәлдә була.

5.4. Килешүдә җайга салынмаган мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җайга салына.

5.5. Килешү Якларның үзара килешүеннән соң, суд карары буенча яки Килешүдә каралган шартлар барлыкка килгән очракта вакытыннан алда өзелергә мөмкин.

5.6. Килешү буенча бөтен бәхәсләр Яклар тарафыннан Министрлыкның урнашу урыны буенча судка мөрәҗәгать итү юлы белән хәл ителә.

5.7. Килешүне имзалап, Башкарма комитет Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан Бүтән бюджетара трансферт бирү шартларының үтәлешен, максатларын һәм тәртибен тикшерүне гамәлгә ашырырга ризалыгын белдерә.

5.8. Килешү тигез юридик көчкә ия 3 нөсхәдә, Министрлык өчен 2 нөсхәдә, Башкарма комитет өчен 1 нөсхәдә төзелде.

## 6. Якларның адреслары һәм реквизитлары

**Татарстан Республикасы**
**Икътисад министрлыгы:**

**Татарстан Республикасы**
**__________________ муниципаль**
**районы Башкарма комитеты:**

Юридик адресы:
Банк реквизитлары:
Банк учреждениесенең аталышы
БИК
к/с
И-х/сч
Шәхси счет:
ИНН / КПП
ОГРН
ОКТМО

Татарстан Республикасы
икътисад министры

_________________/_______________/

Юридик адресы:
Банк реквизитлары:
Банк учреждениесенең аталышы
БИК
к/с
И-х/сч
Шәхси счет:
ИНН / КПП
ОГРН
ОКТМО

Татарстан Республикасы
___________________ муниципаль
районы Башкарма комитеты
җитәкчесе

________________/ _______________/

20____ елның _____________
№ ____ Килешүгә 1 нче кушымта

Грант алучыга чыгым тоту тыелган чаралар исемлеге
Бүтән бюджетара трансфертлар:

- административ биналарны ремонтлау һәм реконструкцияләү;
- администрация биналары өчен җиһазлар сатып алу;
- үләннәрне чабу, агачлар аудару, төпләрен казып чыгару;
- кардан чистарту;
- техника сатып алу (компьютер, принтер, фототехника, музыка җиһазлары һ.б.);
- канцелярия товарлары сатып алу;
- костюмнар, кием-салым, шторалар, портьерлар һәм башкалар тегү;
- ягулык сатып алу;
- гражданлык җаваплылыгын иминиятләштерү;
- вак-төяк авыл хуҗалыгы техникасы һәм инструментлары (триммер, эретеп ябыштыру аппараты, пычкы һ.б.) сатып алу.

Татарстан Республикасының
икътисад министры

_________________/_____________/

Татарстан Республикасы
__________________ муниципаль
районы Башкарма комитеты
җитәкчесе

_________________/ ____________/

20____ елның ______________
№ ____ Килешүгә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булып тормаган, шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән ________________ муниципаль районы авыл җирлекләре һәм шәһәр җирлекләре _____ елгы Бүтән бюджетара трансфертларны юнәлдерергә планлаштырган чаралар исемлеге:

| № п/п | Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән авыл җирлеге/ шәһәр җирлеге исеме | Чараның аталышы | Бүтән бюджетара трансфертны тоту юнәлеше |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| 3. | | | |

Татарстан Республикасының
икътисад министры

__________________/______________/

Татарстан Республикасы
____________________ муниципаль
районы Башкарма комитеты
җитәкчесе

__________________/ _____________/

20____ елның ______________
№ ____ Килешүгә 3 нче кушымта
Формасы
Раслыйм
______________/_________
«_____» ______ 20____ ел

20___ елның «___» ______________ финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы
Бүтән бюджетара трансферт булган чыгымнар турында хисап

Алучының исеме ___________________________________________
Ешлыгы: кварталлык, еллык
Үлчәү берәмлеге: сум (икенче дистә билгесенә кадәр төгәллек белән)

| Күрсәткечнең аталышы | Суммасы | | Чыгымнарны гамәлгә ашыруны раслый торган түләү документлары реквизитлары |
|---|---|---|---|
| | Хисап чоры | Ел башыннан бирле арта баручы йомгагы белән | |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Бүтән бюджетара трансфертның калдык өлеше ел башына, барлыгы: | | | |
| шул исәптән: расланган ихтыяҗ | | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кайтарып бирелергә тиешлесе | | | |
| Килгән акча, барлыгы: | | | |
| шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджетыннан | | | |
| Чыгымнар буенча түләүләр, барлыгы: | | | |
| алардан: | | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылганы, барлыгы: | | | |
| шул исәптән: максатчан билгеләнеше буенча тотылмаганнары | | | |
| штраф санкцияләре кулланылу нәтиҗәсендә | | | |
| Хисап чоры ахырына Бүтән бюджетара трансфертның калган өлеше, барлыгы: | | | |
| шул исәптән: шул ук максатларга юнәлдерүдә таләп ителә | | | |
| кайтарып бирелергә тиешле | | | |

Хисапка түләү документларының тиешле рәвештә расланган күчермәләре теркәлә.
Алучы ________________ _________ __________________________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза)
Башкаручы ________________ _______________ _______________
(вазыйфасы) (Ф. И. А.) (телефон)
«___» __________ 20__ ел

Татарстан Республикасының
икътисад министры

___________________/______________/

Татарстан Республикасы
____________________ муниципаль
районы Башкарма комитеты
җитәкчесе

___________________/ _____________/

20____ елның _____________
№ ____ Килешүгә 4 нче кушымта
Формасы

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләренә һәм шәһәр җирлекләренә грантлар бирү буенча Республика конкурсында җиңүче тарафыннан Бүтән бюджетара трансфертны файдалану турында

**ФИНАНС ХИСАБЫ**

Хәзергесе белән Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булып тормаган, шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләренә һәм шәһәр җирлекләренә Бүтән бюджетара трансферт бирү турында _____________ №______ Килешү нигезендә бирелгән Бүтән бюджетара трансфертны Татарстан Республикасы _____________________ муниципаль районының Татарстан Республикасы муниципаль районнары административ үзәкләре булып тормаган, шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән ___________________________ авыл җирлегенең/шәһәр җирлегенең турыдан-туры тормышны тәэмин итү объектларының матди-техник базасын ныгытуга, Татарстан Республикасы муниципаль районнары административ үзәкләре булып тормаган, шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләрен һәм шәһәр җирлекләрен социаль инфраструктура һәм тышкы төзекләндерү объектлары белән җиһазландыруга һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары административ үзәкләре булып тормаган, шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләренең һәм шәһәр җирлекләренең социаль әһәмиятле бүтән мәсьәләләрен хәл итүгә тотуны раслыйм.

| Чараларның, башкарылган эшләрнең, күрсәтелгән хезмәтләрнең исемнәре, аларны үткәрү срогын һәм аларда катнашучыларны (башкаручыларны) күрсәтеп | Чараларның, эшләрнең башкарылуын яки хезмәтләрнең күрсәтелүен раслый торган документларның исемнәре һәм реквизитлары | Барлыгы, сум |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | ҖӘМГЫСЕ: |

Хисапка документларның тиешенчә таныкланган түбәндәге күчермәләре беркетелә:
1. Әлеге хисап белешмәләренраслаучы документлар _____ биттә, ____нөсхәдә.

Татарстан Республикасының
икътисад министры

__________________/____________/

Татарстан Республикасы
___________________ муниципаль
районы Башкарма комитеты
җитәкчесе

___________________/______________/

20____ елның ______________
№ ____ Килешүгә 5 нче кушымта

Хисапка тапшырыла торган документлар
**ИСЕМЛЕГЕ**

- финанс хисаплары (шартнамәләргә кушымталар – төп нөсхәләр);
- аукционга йомгак ясау беркетмәләре (таныкланган күчермәләре);
- муниципаль контрактлар (таныкланган күчермәләре);
- шартнамәләр (таныкланган күчермәләре);
- локаль ресурс смета исәп-хисаплары (таныкланган күчермәләре);
- счет-фактуры (таныкланган күчермәләре);
- түләү счетлары (таныкланган күчермәләре);
- товар накладнойлары (таныкланган күчермәләре);
- ярашлылык сертификатлары (таныкланган күчермәләре);
- башкарылган эшләрнең бәясе турында белешмәләр (таныкланган күчермәләре);
- башкарылган эшләр турында актлар (таныкланган күчермәләре);
- банкларның түләү йөкләмәләре (финанс-бюджет палатасы мөһере белән);
- эш башланганчы, эшләр барган вакытта һәм төрле ракурслардан һәр чараның фотолары.

Сатып алынган техникага өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшырырга кирәк:
- паспорт (таныкланган күчермәсе);
- гарантия талоннары (таныкланган күчермәләре);
- кабул итү-тапшыру актлары (таныкланган күчермәләре);
- теркәү турында таныклык (таныкланган күчермәсе);
- техник карау узу турында таныклык (таныкланган күчермәсе);
- Татарстан Республикасы муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән авыл җирлеге/ шәһәр җирлеге балансына транспорт чарасы (таныкланган күчермә) кую турында боерык;
- фотолар (шул исәптән номер билгеләре белән).

Татарстан Республикасының
икътисад министры

__________________/______________/

Татарстан Республикасы
____________________ муниципаль
районы Башкарма комитеты
җитәкчесе

__________________/______________/